| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» 02 2024 ел № 77

Махсус хәрби операциядә (МХО) катнашучыларның
Балтач муниципаль районы мәдәният һәм мәгариф учреждениеләре үткәрә
(оештыра) торган чараларга бушлай кертелүе турында

Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 16 мартындагы 121 номерлы «Россия Федерациясендә социаль-икътисадый тотрыклылыкны һәм халыкны яклауны тәэмин итү чаралары турында»гы Указы, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга (МХО) Балтач муниципаль районы мәдәният һәм мәгариф учреждениеләре үткәрә торган чараларга бушлай кертүне билгеләргә, атап әйткәндә:

1.1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә музейларга бушлай керү;

1.2. Спорт объектларына бушлай керү - тренажер залы булган «Дулкын» ябык йөзү бассейны һәм спорт заллары;

1.3. Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты буйсынуындагы учреждениеләр уздыра торган мәдәният - ял чараларына, мәдәни - тамаша кылу һәм мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә башка чараларга түләүсез йөрү.

1.3.1.Урыннарны билгеләп утырту каралган чараларга билетларны алдан ук броньларга киңәш ителә. Әлеге карарның 1.3 пунктында каралган социаль ярдәм чарасына хокук алу өчен чарага кадәр 5 календарь көннән дә соңга калмыйча учреждение кассасына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Буш урыннар булганда чарага билетлар биреләчәк, чарага буш урыннар булмаган очракта, чаралар исемлегендә китерелгән башка чараларга килергә тәкъдим ителә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында каралган социаль ярдәм чаралары гражданинның «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы карары нигезендә Россия Федерациясе Хәрби көчләрендә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәт узу чорына каралган.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач

муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач районы мәдәният бүлеге башлыгына һәм «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район Башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов